РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 июля 2023ел. № 517

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы территориясендә Терекөмөшле лампалар туплану урынын булдыру турында**

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында " 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Тирә-яктагы мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварендагы 7-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендагы 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Яктырткыч җайланмаларын, электр лампаларын җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру тиешенчә булмау, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булганга, аларны җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 елгы 2314 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә район судының 20.06.2023 елгы карарын үтәү максатыннан, Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты **карар итә:**

1. Терекөмөшле лампалар кулланучылар өчен, шул исәптән күп фатирлы йортларның милекчеләре, яллаучылары, биналардан файдаланучылар өчен, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы территориясендә терекөмөшле лампалар туплану урыны - Татарстан Республикасы, Әтнә районы, Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 1 йорт адресы буенча, Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы янында урнаштырылган капкачлы металл контейнер билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы территориясендә терекөмөшле лампалар туплау урынының урнашуы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.ru.) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А. Ф. Каюмов